
Чаллы - дуслар каласы: [Яр Чаллы шәһәренең М. Җәлил исемендәге Үзәк китапханәсендә җирле халыкларның милли мәдәниятен һәм әдәбиятын чагылдырган «Чаллы - дуслар каласы» фестивале узды] // Шәһри Чаллы. – 2026. – № 15 (4 март). – Б. 3.



# Чаллы – дуслар каласы

**25 февральдә Муса Җәлил исемендәге үзәк китапханәдә җирле халыкларның милли мәдәниятен һәм әдәбиятын чагылдырган «Чаллы – дуслар каласы» («Многоликие Челны») фестивале узды.**

Чарага килүчеләр төрле милли оешма вәкилләре чыгышларын тыңладылар, мәдәни мирасны саклауның мөһимлеге һәм әһәмияте хакында фикер алыштылар.

Фестиваль кысаларында әдәби мәйданчыклар да эшләде. Шагыйрә Сирень Якупова, рәссам-сынчы Хәмит Латыйпов белән «түгәрәк өстәл»ләр оештырылды. Шәһәрдәшләр аларга сорауларын бирделәр, иҗатлары белән таныштылар. Урында ук Чаллыда яшәп иҗат итүче язучыларның китаплар күргәзмәсе дә тәкъдим ителде.

Оештыручылар белдерүенчә, Чаллы җирендә көн күрүче милләтләргә хөрмәт хисе тәрбияләү максатында оештырылган фестивальдә һәркем газиз ана телен, мәдәниятен саклауга үз өлешен кертә алды. Халыклар дуслыгын ныгытуга багышланган әлеге чара киләчәктә дә оештырылачак.